УДК 579

***Н.В. Феоктистова***

# ТАТАР МИКРОБИОЛОГЫ Р.Г. САЙМАНОВАНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

В 2012 году ушла из жизни выдающийся микробиолог, доцент Казанского университета Роза Габдрахмановна Сайманова, ученая с постоянным позитивным настроем и доброжелательным отношением к людям в любых обстоятельствах. Статья посвящается памяти этой уникальной личности, представительнице татарской интеллигенции. Автор освещает жизнь и научную деятельность Р.А. Саймановой, делится с воспоминаниями ее современников. В 1939 г., окончив школу с отличными отметками, Роза поступила на кафедру физиологии растений и микробиологии биологического факультета КГУ. Педагогический стаж Розы Абдрахмановны составляет 44 года. В 1964 г. Р.А. Сайманова защитила кандидатскую диссертацию «Дезоксирибонуклеазы бактерий и влияние некоторых условий на их образование и активность». Непосредственное участие Роза Абдрахмановна принимала в восстановлении в 1947–1948 гг. производства на Казанском уксусном заводе, в 1956–1963 гг. руководила работами по изучению грибной коррозии оптических приборов, выпускаемых Казанским оптико-механическим заводом. Большую роль она сыграла и в развитии научного направления «Сельскохозяйственная микробиология». Автор статьи представляет Розу Абдрахмановну как талантливого педагога и общественного деятеля, стремящегося передать любовь к жизни и избранной профессии не только своим ученикам, но и всем людям в ее окружении.

**Ключевые слова:** выдающийся микробиолог, педагог, татарская интеллигенция, научно-педагогическая деятельность.

In 2012 an outstanding microbiologist, associate professor of Kazan University Roza Gabdrakhmanovna Saymanova, a scientist with a constant positive attitude and a benevolent attitude towards people in any circumstances passed away. The article is dedicated to the memory of this unique personality, a representative of the Tatar intelligentsia. The author covers the life and scientific activities of R.A. Saimanova, shares with the memories of her contemporaries. In 1939 after graduating from school with excellent marks Rosa entered the Department of Plant Physiology and Microbiology, Faculty of Biology, KSU. Rosa Abdrakhmanovna's teaching experience is 44 years. In 1964 R.A. Saimanova presented her Ph.D. thesis «Deoxyribonuclease of bacteria and the influence of certain conditions on their formation and activity». Roza Abdrakhmanovna took direct part in the restoration in 1947–1948 of production at the Kazan vinegar plant, in 1956–1963 supervised work on the study of fungal corrosion of optical devices produced by the Kazan Optical and Mechanical Plant. She also played an important role in the development of the scientific direction «Agricultural Microbiology». The author of the article presents Rosa Abdrakhmanovna as a talented teacher and public figure who strives to convey the love of life and her chosen profession not only to her students, but also to all people in her environment.

**Keywords:** outstanding microbiologist, teacher, Tatar intelligentsia, scientific and pedagogical activity.

2012 елда күренекле татар зыялысы, тормышта һәрчак уңай кәеф-халәтен һәм кешеләргә хәерхаһлы мөнәсәбәтен саклый белгән уникаль шәхес, күренекле микробиолог, Казан университеты доценты Сайманова Роза Габдрахман кызы бакыйлыкка күчте.

Роза Сайманова (Хәбибуллина) 1921 елның 18 августында Вятка губернасы (хәзерге Киров өлкәсе) Малмыж шәһәрендә укытучылар гаиләсендә дөньяга килә. Казан шәһәрендә укыган әти-әниләре (әтисе Хәбибуллин Габдрахман Хәбибулла улы – 1914 елны реаль училище; әнисе Мансурова Рәкыя Фәйзрахман кызы, 1916 елны хосусый хатын-кызлар гимназиясен тәмамлаган) авылда укыталар, 1920 елда Халык мәгарифе бүлеге аларны Малмыж шәһәренә эшкә җибәрә. Габдрахман Хәбибулла улы яңа гына оешкан 7 еллык татар мәктәбенә директор итеп билгеләнә. Моннан тыш, ул биология һәм химия предметларыннан дәресләр бирә, әниләре татар теле һәм әдәбияты укыта.

1931 елда Хәбибуллиннар гаиләсе Казанга күченә. Кечкенә Роза 18 номерлы (10 еллык) татар мәктәбендә укуын дәвам итә. Әтисе, Казан университетының биология факультетында читтән торып укучы студент буларак, Казан кооператив техникумында химия укыта. Укытучылык эше аның гомерлек язмышына әверелә. Әнисе, бераз вакыт Казанның Ленин районы мәгариф бүлегендә инструктор булып эшләгәннән соң, сәнгатькә кереп китә һәм 20 ел буе Казан курчак театрында актриса булып эшли.

1939 елда мәктәпне гел бишле билгеләренә тәмамлап, Роза Казан университеты биология факультетының үсемлекләр физиологиясе һәм микробиология кафедрасына укырга керә. Микробиология аны кызыклы һәм перспективалы белгечлек буларак үзенә җәлеп итә.

Роза Хәбибуллинаның остазлары – дөньякүләм билгеле Н.И. Ливанов, В.И. Баранов, А.М. Алексеев кебек галимнәр. Яшь кыз аларның лекцияләренә һәм лаборатор дәресләргә яратып йөри.

1941 елның 12 июнендә биология факультетының икенче курс студентлары җәйге сессиянең соңгы имтиханын тапшыралар. Әмма каникулларга таралырга өлгермиләр, 1941 елның 22 июнендә Бөек Ватан сугышы башланып китә. Озак та үтми, Казан университеты каршындагы комсомол комитетында кыска вакытлы (2,5 айлык) сандружина курслары оеша, анда, нигездә, биологлар һәм химиклар шөгыльләнә. Әлеге курсларга Роза Хәбибуллина да кабул ителә. Аны медицина хезмәтенең кече сержанты дәрәҗәсендә Казанга Ленинград фронтыннан эвакуацияләнгән 1667 номерлы нейрохирургия госпиталенә беркетәләр, биредә ул 3 елга якын шәфкать туташы булып эшли. Бу госпитальдә башлары, умыртка баганасы яки кул-аяклары каты яраланган сугышчылар дәвалана, шуңа да тәүлекнең күп өлешен шәфкать туташлары госпиталь ятаклары янында дежур торып уздыра. Аның хезмәт сөючәнлеге, игътибарлылыгы, түземлелеге һәм иң авыр пациентларны да тернәкләндерә белү сәләте госпиталь табибларының игътибарыннан читтә калмый, алар Розага университет биофагыннан медицина институтына күчәргә тәкъдим итәләр.



Р.Г. Сайманова

1943 елның башында биология факультеты деканы профессор М.В. Марков сугыш башлану сәбәпле укуларын өзәргә мәҗбүр булган студентларны барлый башлый. Беренче сентябрь көнне дәресләргә 1941 елда икенче курсны тәмамлаган 90 студентның нибары 27 се генә килә. Күпләр фронтта ятып калган, кемнәрдер, сугыш башлануга, йөрәк кушуы буенча, Татарстанның төрле районнарына укытырга киткән һәм Казанга әйләнеп кайтмаган.

Университетка җыйналган студентлар арасында Роза Хәбибуллина да була. Дәресләргә йөрү белән бергә, ул госпитальдә дә эшләвен дәвам итә. Сугыш чоры авырлыкларына карамастан, Роза максатына туры бара.

1946 елда Роза Хәбибуллина «Әче-сөт бактерияләрендә бактериофаглар» дигән темага диплом эше яклый; сәләтле һәм гаять җаваплы студент кызны профессор М.В. Марков күреп ала. Нәкъ менә шушы галим Розаны Казан университетының үсемлекләр физиологиясе һәм микробиология кафедрасына өлкән лаборант итеп эшкә алырга тәкъдим итә.

Роза Хәбибуллинаның педагоглык стажы 44 ел. 1949 елдан ул – ассистент, 1964 елдан – үсемлекләр физиологиясе һәм микробиология кафедрасы доценты. 1940 еллар ахырыннан 1960 еллар уртасына кадәр биология факультетында микробиологиягә караган дисциплиналарны ике белгеч – М.И. Беляева һәм Р.Г. Сайманова укыта. Роза Габдрахман кызы микробиология, туфрак микробиологиясе, санитар-азык микробиологиясе буенча лекцияләр укый, төп микробиология дисциплиналарыннан гамәли курсларны алып бара. Хәзерге вакытка кадәр кафедрада укып чыккан белгечләр аның лаборатор дәресләрдә студентларны сәнәгатьтә, биохимия белән бәйле җитештерү өлкәләрендә кулланыла торган микробиологик процесслар, бигрәк тә әчүнең төрле төрләре белән таныштыра торган зур практикумын искә төшерәләр.

Университетта Роза Габдрахман кызының турыдан-туры катнашлыгында йөзләгән югары квалификацияле микробиологлар әзерләнә. 1964 елда Р.Г. Сайманова «Бактерияләрдәге дезоксирибонуклеазлар һәм аларның барлыкка килүенә, активлыгына тәэсир итә торган кайбер шартлар» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый.

Р.Г. Сайманова (Хәбибуллина)– группаларның иң яхшы кураторларыннан, 33 ел дәвамында биология-туфрак факультеты Гыйльми Советының алыштыргысыз Гыйльми сәркатибе. Күп еллар дәвамында Роза Габдрахман кызы микробиология кафедрасының уку-укыту бүлеге мөдире вазифасын да башкара. Озак вакытлар М.И. Беляева белән бергә эшләп, Роза Габдрахман кызы аның фикердәше генә түгел, дустына әверелә. Маргарита Ильинична белән бергә ул суны әчетә торган

бактерияләрне өйрәнә, микроорганизмнарның саф культуралары музеен булдыра, микроблы нуклеодеполимеразларны тикшерә.

Роза Габдрахман кызы 1947–1948 елларда Казан уксус заводында җитештерү эшен тергезүдә катнаша, 1956–1963 елларда Казан оптика-механика заводында җитештерелә торган оптик приборлардагы гөмбәчек коррозиясен өйрәнү эшенә җитәкчелек итә. «Авыл хуҗалыгы микробиологиясе» фәнни юнәлеше үсешендә дә аның роле зур.

Р.Г. Сайманова (Хәбибуллина) микробиология лабораториясенең «йөзен» билгеләүчеләрнең берсе буларак бәяләнергә хаклы. 1953–1958 елларга туры килгән студентлык чарын биология фәннәре докторы, әйдәп баручы гыйльми хезмәткәр Ф.Г. Куприянова-Ашина болай дип искә төшерә: *«Без – Инна Лещинская һәм мин – микробиология лабораториясендә беренче курстан шөгыльләнә башладык. Дәресләрдән соң киләбез дә төнгә кадәр шунда утырабыз. Лабораториягә кайчан кермә, анда һәрвакыт иҗади һәм хәерхаһлы атмосфера тудыра алган Маргарита Ильиничнаны һәм Роза Габдрахмановнаны очратасың. Роза Габдрахмановна безне микробиолог хезмәтенең асылына һәм барлык нечкәлекләренә өйрәтте. Төгәллеккә, пөхтәлеккә, тәҗрибәләр уздырганда җентекле карарга ул күнектерде. Соңрак, җитди рәвештә фән белән шөгыльләнә башлагач, бу сыйфатлар безгә нык ярдәм итте»*. Р.Г. Сайманова эшчәнлеге замандашлары тарафыннан галим буларак та, кеше буларак та әнә шулай югары бәяләнә. Моннан тыш Роза Габдрахман кызы үзенең педагоглык «серләре» белән болай дип бүлешә торган була: *«Гамәли дәресләрдә мин һәрчак микроскоп ярдәмендә препаратлар тикшерүче студентларның күзләренә карыйм. Микроорганизмнарны, бигрәк тә алар тере һәм буялмаган булганда, күзәтү шактый авыр. Кешенең чыннан да иң кирәклесен күрүен яки болай гына сөйләвен ничек итеп аерырга соң? Әгәр микроскопка текәлгән күзләрдә шатлык чаткысы ялтыраса – димәк, күреп алган!»*.

Микробиология кафедрасы инженеры Н.К. Мочалова исә болай дип искә ала: *«1977 елны Казан университетын тәмамлагач, мине микробиология кафедрасында өлкән лаборант итеп эшкә калдырдылар. Беренче көннән үк Роза Габдрахмановна минем остазыма, укытучыма һәм, гомумән, бик якын кешемә әйләнде. Ул гаять зур тәҗрибәгә ия булып, микробиологиянең төрле өлкәләреннән тирән белемле иде. Роза Габдрахмановна мине үз вазифаларымны намус белән һәм төгәл башкарырга өйрәтте, нәрсәдер аңлашылмаганда, һәрчак ярдәмгә килә иде.*

*Мине аның гамәли дәресләрне ничек җентекләп һәм җитди әзерләве гаҗәпләндерә иде. Башта ул бик төгәл һәм аңлашылырлык итеп сөйли, ә инде студентлар мөстәкыйль эшкә керешкәч, һәрберсе янына килә һәм тагын бер кат аңлата-күрсәтә, студентларның эшне ничек башкаруын күзәтеп тора. Шул рәвешле генә чын микробиологлар тәрбияләргә мөмкин, дип саный иде ул. Ул бер минутка да студентларның үзләрен генә калдырмый, ә бит кайвакыт гамәли дәресләр көненә 3–4 пар булып баралар. Роза Габдрахмановна үзе*

*гамәли дәресләргә җаваплы якын килә һәм башкалардан да шуны ук таләп итә иде. Һәр студент барлык кирәк-ярак белән тәэмин ителгән булсын, берәрсенә нидер җитми калса – бу инде гадәттән тыш хәлгә әйләнә. Җитешмәгән нәрсәләрне эзләп, мин алдан ук башка кафедралар буйлап йөгерәм, дәрес башлануга тулы әзерлекне тәэмин итәргә тырыша идем.*

*Роза Габдрахмановнаның эшкә сәләте таң калдыра иде. Уку-укыту белән шөгыльләнүе өстенә, ул әле кафедраның уку планнары белән утырырга вакыт таба, озак еллар факультет Гыйльми советының сәркатибе булды».*

Роза Габдрахман кызы – үз укучыларында сайлаган һөнәрләренә мәхәббәт хисе уятуга зур игътибар биргән талантлы педагог. Аның лекцияләре төгәллеге, логик төзеклеге белән аерылып тора һәм бер генә дәреслектә дә булмаган мисаллар белән баетылган була. Гамәли дәресләре барлык ваклыкларына кадәр уйланган, үзе һәрбер студент төшенерлек итеп аңлата белә. Шул ук вакытта Роза Габдрахман кызы – һәрчак ачык һәм яхшы күңелле, студентларга, хезмәттәшләренә карата да чиктән тыш түзем, сабыр, ярдәмчел кеше иде. Аның архивында сугыштан соңгы еллардан башлап биология-туфрак факультеты һәм микробиология кафедрасы чыгарылышларының фоторәсемнәре кадерләп саклана.

Роза Габдрахман кызы 69 яшендә укыту эшеннән китә – моңа сәламәтлеге сәбәпче була, ләкин ул микробиология кафедрасында консультант һәм факультет Гыйльми советы сәркатибе булып эшләвен дәвам итә. 1998 елда лаеклы ялга китә, әмма университет тормышыннан аерылмый, барлык вакыйгаларда катнаша, укучылары һәм элеккеге коллегалары белән аралашып яши.

1943 елда Р.Г. Сайманова ТАССР Югары Советы Президиумының «Яралыларны тернәкләндерү буенча иң югары күрсәткечләргә ирешкән өчен» Мактау грамотасы белән бүләкләнә, ә 1945 елны аңа «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында фидакяр хезмәт өчен» медале тапшырыла. Аның бүләкләре арасында – «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 50 ел» һәм «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 60 ел» юбилей медальләре дә бар.

Роза Габдрахман кызының югары белем бирү өлкәсендәге хезмәтләре «Фидакяр хезмәт өчен, В.И. Ленинның тууына 100 ел тулу уңае белән» (1970) юбилей медале, СССР Югары һәм урта махсус белем министрлыгының «Югары квалификацияле белгечләр әзерләү, фәнни тикшеренүләрне үстерүдәге күпьеллык нәтиҗәле хезмәт өчен, Казан дәүләт университетының 175 еллыгы уңае белән» (1979) Мактау грамотасы, «Хезмәт ветераны» (1985) медале, СССР Югары һәм урта махсус белем министрлыгының «Хезмәттәге казанышлар өчен» (1990) күкрәк билгесе белән дә билгеләнгән.

***Феоктистова Наталья Владимировна,***
*биология фәннәре кандидаты*